# КАРАК МУЛЛА

## I

Бөтен тирә-як халкы аның исемене ишетү берлән калтырый башлый, һәркем анлар хакында:

— Нәселләре берлән карак инде анлар... Ходай кабереңне якын кылмасын, — дип сыгына.

Картлар тәфсил бирә[1]:

— Анларның бер бабасы, юлаучылар төшергән булып, үзенә кунарга килгән зур байларны талый торган иде. Үзе үлгәч, коесыны тазартканнар икән, әллә ничә адәм башы, адәм гәүдәсе чыккан... Сөйләсәң, мәрхүмне яманлык берлән яд итү була. Төндә кергән бай юлаучыларны үтереп, мал вә акчаларын ала да икән, гәүдәләрен, таш бәйләп, коега йибәрә икән, ди... Ә бер агалары, көпә-көндез Тора тауда бер байны суеп, катрга[2] китте... Алла үзе хөкем итсен, бичаралар, ата-бабадан шулай киләләр... — диләр.

Караклык берлән даны чыккан бу нәсел, мал урлау берлән генә түгел, болай усаллык, батырлык һәм бик аз нәрсә өчен дә дөнья җимереп үч алучылык, куәтлелек һәм зур гәүдәлелек берлән дә атаклылар иде. Халык бунлар хакында «кан түкми тора алмыйлар» дигән бер мәкаль дә чыгарган. Бөтен шул сыйфатлары өстенә анларның һәммәсе табигый гакылда халыктан өстенлек һәм барысы да укый-яза белерлек кадәрле мәктәп күргән булучылык берлән дә аерылалар иде.

Әмма һичберсе, укуыны шул ибтидаи[3] мәртәбәдән үткәреп, югарырак китүне уйламый иде. Ләкин, ни сәбәпберләндер, гыйлемнән ләззәт алыпмы, башка бер уй берләндерме, арадан берсе ераграк бер шәһәрнең зур бер мәдрәсәсенә укырга килеп керде. Буны, өендә вә бөтен авылдагы шикелле, мәдрәсәдә дә «Тимри» дип атыйлар иде.

Тимри дәрескә бик шәп, хәтта укымыйча ук белүче булганга, бу мәдрәсәдә аның кайдан килгән вә кайсы якныкы икәнене белә торган һичбер якташы булмаганга, яшьрәк, куркаграк шәкертләр: «Ул җен имеш, мәдрәсәдәге һәрбер кырык шәкертнең кырык беренчесе җен була имеш...» дип сөйлиләр, ләкин һичкем буны үзенә әйтергә батырчылык кыла алмый иде. Чөнки ул һәркемне бөтен шәкерт алдында яндырып сүгәргә, аның белә дә канәгатьләнмәсә, ни очраса, шуның берлән алып башына салырга хәзер иде. Шунлыктан һәр шәкерт тә, «аның белән бәйләнмәү хәер» дип, эчтән тынарга мәҗбүр була иде.

---

[1]*Тәфсил бирә* — җентекләп сөйли, аңлатып бирә.
[2]*Катрга* – каторгага.
[3]*Ибтидаи* — башлангыч.

Ул байтак заманнар бу мәдрәсәдә яшәде. Дәрвиш табигатьле бер хәлфәнең тәгъбиренчә, «усаллыгы вә имансызлыгы йөзенә чыгып» торса да, тотып җәза кылырлык һичбер эше сизелмәде. Соңгы көннәрдә мәдрәсәдән яхшы толыплар, яңа калушлар байтак кына югалгаласа да, кемнән икәне беленми, һәркемнең эчендә Тимридән шикләнү бик төпле рәвештә булса да, берсе дә тышка чыгара алмый иде.

Бервакыт Тимринең мәдрәсәдән китәчәк хәбәре таралды. Һәм шул ук хәбәр берлән бергә мәдрәсә карарга кергән бер байның кыйммәтле туны берлән берәүнең яхшы җөббәсе[1] урланганлыгы мәсьәләсе бөтен мәдрәсәнең астыны өсткә китерде.

Чаптылар талчукка[2]!

— Шундый, шул сыйфатлы тун белән, фәлән рәвешле җөббә саткан адәм күрмәдеңезме?

Башта берәү дә белмәде. Җыелды талчукчылар, сорыйлар, сорашалар: юк, берәү дә алмаган да, күрмәгән дә.

Килә бер карт:

— Ни бар, нигә җыелыштыңыз?.. Ни мал, кая мин дә катышам!

— Юк, бабай, бунда алырга түгел, урланган малны табарга кирәк...

Картка мәсьәләне сөйләп, урланган малны сыйфатлап бирәләр. Ул бер генә секунд уйлана да, «ә... белдем» дип, шәһадәт бармагыны[3] югары күтәреп, яшерен бер хәл сизгән адәм кыяфәте берлән, тун вә җөббәне эзләп килгән адәмне читкәрәк алып барып, колагына гына әйтә:

— Мин әйтте димә, агай-энедән яхшы түгел, шундый ике нәрсәне бая минем алдымда Камалига китереп бирделәр. Башкача эзләмә, политсә[4] ал да, туры шуның складында тентү ясат! — ди.

Мәсьәлә шуның берлән тиз очына чыгып, тун берлән җөббәне табалар.

— Камалига кем китереп биргән?

Бу сөаль бөтен мәдрәсәне вә бөтен талчукны зур тәшвишкә салды. Камали: «Мин кем икәнен танымыйм, берәү сатам дип китергәч, алдым да калдым тагы. — Безгә ни?.. Аның караклыгы маңлаена язылмаган... Мин аны кайдан белим», — ди.

Аны мәдрәсәгә алып киләләр дә һәммә шәкертне аның күз алдыннан үткәрәләр:

— Бу түгелме сиңа тун саткан кеше?

Ул: «Кич иде мин алганда, яхшылап карый да алмадым. Шулай да менә шул икенең берсенә охшый иде», — дип, бик юаш вә бик суфи ике шәкертне

---

[1] *Җөббәсе* – кием (җиләннең бер төре).
[2] *Талчукка* – иске-москы әйберләр сатыла торган базарга.
[3] *Шәһадәт бармагыны* — имән бармагын.
[4] *Политсә* – полиция.

күрсәтә. Бунлар шундый бәндәләр ки, андый куәтле караклыкка хас бер эшне эшләү түгел, гомерләрендә бер каләм урларга да батырлыклары йитмәячәк.

Хәзрәт тә, бөтен шәкерт тә буны беравыздан рәд кылалар[1]:

— Син күзеңне ачып кара: бунлар юлда яткан алтынны алудан да курка торган адәмнәр... — диләр.

Камалидан соң, бик ялынып, бик тугрылыгыны теләп, теге картны китерәләр. Ул, ишектән керү берлән, Тимрине күрә дә, «Менә тун сатучы кеше!» — ди...

Тимри картка берни дими, танымый, оялмый; бөтен усаллыгы вә эчендә булган барлык үч алу вә дошманлык куәсе җыелган ике зур ала күзе берлән картка ниһаясез ачу катыш бер ташлана да борылып китә.

Хәзрәт, политсәгә-фәләнгә хәбәр ителмәве берлән әмер итеп, дәресханәгә керә.

Тимри, үзенең йөзенә, күзенә бөтен усаллыгыны, ачуыны чыгарып, урынына килә дә әйберләрене җыя башлый. Шәкертләр башта эчтән генә, шыпырт кына сөйләшәләр. Бәлки шул хәлдә озак та барыр иде, бер казый килеп, аңар: «Изәм мин синең башыңны!» — дигән шикелле, батыраеп сүз ача. Шәкертләр, берьюлы йиңеллек хис итеп, аның тирәсендә әтәчләнергә тотыналар.

Бөтен вөҗүде[2] мәдрәсә хәмияте[3] берлән тулган зур, калын бер мишәр шәкерте тай боты шикелле таза беләкләрене сызганып килә дә, каты, ярты һәм сынык теле берлән:

— Син... оятсыз... мәдрәсәнең атын сатып йөрисең килә... икән... явыз... — дип, яңагына салып йибәрә. Ул егылыйм дигәндә, икенче яктан тагы берне бирә. Мәдрәсә хәмияте берлән кайнаган егетләр берәм-берәм үз кулларының куәтене сыныйлар. Икенчеләр, өченчеләр теге мишәр артыннан өстиләр. Берара кызу, куәтле кыйнап та ташлыйлар. Бәлки нәтиҗә яман да булыр иде. Тимринең ачы вә яман тавышы берлән:

— Кеше үтерергә җыендыңызмыни, подлислар... карауууул!.. — дип акыруына дәресханәдән хәзрәт йөгереп чыгып, шәкертләрне таратты. Шуннан соңгы эш хәзрәт, хәлфә кулына калды.

Анлар бундый башбаштаклык берлән түгел, шәригать берлән хөкем итмәкчеләр:

— Тимри, кырык камчы сугылып, тәүбә итәргә күнәсеңме, әллә мәдрәсәдән китәсеңме? — икенең берсе! — диләр.

---

[1]*Рәд кылалар* — кире кагалар.

[2]*Вөҗүде* — яшәеше.
[3]*Хәмияте* — саклау тойгысы.

Теге, бая картка караган кеби, ачу вә дошманлык берлән тулган зур ала күзләрене хәзрәт вә хәлфәгә куәт берлән бер ташлый да ачудан кысылган теш арасыннан:

— Сугасыңыз килә икән... биреңез минем билетымны! — ди. Тун сатып алган акчаны өстләренә ташлый да тагы куша:

— Әйтерсең, мәдрәсәләреннән куып, миңа бик зур эш кылалар... Мәдрәсә бетмәгән әле. Унбиш тиенгә извощик[1] яллыйм да, башка мәхәлләнекенә барам... Кууыңызның бөтен зарары — шул унбиш тиен! — ди. Ул җыена, төренә дә икенде-ахшам арасында чыгып китәчәк була — мәдрәсәдән куыла.

Аның куылачагыны белгәнгә, һәрбер шәкерт мәсҗедкә бармый, башка йиргә дә китми; һәммәсе аның торган бүлмәсенә тыгылып, күзләрене аңар кадап торалар.

Ул, әйберләрене күтәреп, һичкемгә карамый вә һичберәүгә дәшми атлаганда, кайбер шәкертләр арттан, яшеренеп, сызгырган булалар. Яшьрәкләр:

— Тимри, Тимри... Кәвеш карагы, кәвеш карагы, карак... карак!.. — дип кычкырып калалар.

Берничә шәкерт, иске подносларны барабан ясап, дөбер-шатыр кагалар, дөбердәтәләр...

Баягы ике юаш, суфи шәкерт, яннарына берничә бала алып, Тимринең артыннан аңар таба ташлар, иске чүпрәкләр атып калалар. Берсе иң ахырдан аның өстенә каратып иске чабата ыргыта.

Ул китә.

Шуның китүе берлән бергә барлык шәкерт өстләреннән бер авырлык төшкән яки араларында яшерен генә дәвам кылган бер куркынычтан котылган кеби бер хәл хис кылалар.

**II**

Ул: «Унбиш тиенгә извощик яллыйм да икенче мәхәллә мәдрәсәсенә барам», — дисә дә, сүзендә тормады, үзенең мәдрәсә вә шәкертлек рамкаларына сыя алмавыны белепмедер, укуыны шул ноктада катгыян[2] кисеп, туры үз авылына китте.

Бу кайтканда, авылларының мөәзине авырый иде, «әһле гыйлем»нән[3] буңа башка адәм булмаганга, картлар буны мөәзинлек хезмәтенә куша башладылар. Ул азан әйтә, камәт төшерә[4], Коръән укый, җеназага йөри — шунларга җавап уларак, аның үзене «вакытлы мөәзин» сыйфаты берлән

---

[1] *Извощик* – извозчик.
[2] *Катгыян* — тәмам.
[3] *Әһле гыйлемнән* — гыйлем ияләреннән.
[4] *Камәт төшерә* — намазга керешү алдыннан аягүрә укыла торган доганы уку.

муллалар рәтеннән ашка-суга йөртәләр иде.

Ул бунларның «үз эше» булмавыны бик ачык сизә, шулай да эшли иде, чөнки ел бик бай, халыкта юмартлык вә кунакчылык бик зур, тик ятканчы, доход булыр, ди иде. Халык исә, нәселенә вә аның күзенә, йөзенә чыгып торган имансызлыгына карап, мәсҗед әһле булмавыны эчтән хис кылсалар да, бердән, башка адәм булмаганга, икенчедән, «ерак шәһәрнең мәдрәсәсендә голәма тәрбиясендә яшәү» аны, бәлки, төзәткәндер; ул, бәлки, нәселенең мөстәснасы[1] булыр, дип уйлап, аның төшергән камәтләренә намаз укып йөриләр иде.

Бу хезмәт аңар яхшы ук файдалы, ягымлы булып чыкты. Үзенең дә вә халыкның да көткәненә каршы ул яхшы мөәзин булып китте. Кайбер вакыт эшләр һәммәсе бер нәтиҗәгә карап агалар.

Бунда да шуңар охшаш бер хәл булып, мөәзин вафат булды да, Тимрине аның урынына сайладылар.

Халык эчтән көлә, бер мөнәсәбәтсезлек сизенәләр, ләкин тыштан һәркем: «Бер минем өчен генә түгел, илгә ярагач, бер миңа ни калган!» — дип, дәшмиләр, аның мөәзин булу мәсьәләсе чыккач, бар да, ирексез, тамга салганнар иде.

Бу бик яхшы мөәзин иде. Мәсҗеднең утыныны-фәләнене ташырга кирәк булса, әүвәлге мөәзиннәр кеби, мәхәллә картларына әйтеп, җыен җыйдырып маташмый; баерак адәмнәргә бара да, көчләп җиктергән кеби, атларыны җиктереп, малайларыны урманга йибәрә, башка тугрыларда да шуңар охшаш эшләр кыла; мәет-фәлән була калса, янына әллә ничә кеше җыеп мәшәкатьләнми, ялгызы да, җырлап, төнәтә иде.

Мулла карт иде, куркак иде. Эчтән начарлык сакласа да, тыштан ялтырап, нәселләрене үз ягына аудару өчен, Тимрине үз янына иптәш мулла ясатырга күнде. Шулай итеп, ул, бик гади агым буенча барып, мәхәлләнең михрабына, мөнбәренә чикле йитте.

Берничә ел үтә. Ул тәмам урынлашып бара.

Башта ару кеби, ул-бу юк кеби, тимер балавызга бөтенләй әйләнде кеби күренә иде. Ләкин бу хәл озакка бармады. Менә бервакыт тирә-як авылларда Тимри мулланың бик үк яхшы булып йитмәгән адәмнәр берлән катышкалавы, фәлән вакытны бер шөбһәле адәмнең, аңар бик караңгы төндә килеп, өенә дә керми, чәй-фәлән дә эчми киткәнлеге, шуңар охшашлы дәхи берничә вакыйганың булганлыгы сөйләнә башлый; картлар эчләреннән генә аның үз нәселенә тартуы хакында уйлый башлыйлар.

Бу «уй», бу «сүз»ләрнең растлыгыны ихтималлаткан берничә эшләр дә

[1]*Мөстәснасы* — чыгармасы.

ялтырап кала. Бу мәсьәлә киңәеп, бервакыт Тимри мулланың «капчык булуы», ягъни урланган малны җыеп ятуы хакындагы хәбәр бөтен тирә-якта, идән астыннан булса да, йөри башлый. Аның күгендә заһир булган[1] бу кара болыт, һаман зурая-зурая барып, ниһаять, Тимринең угырлаша башлавы ачык сөйләнә — шуның артыннан барып, мәсьәлә аның «указын алырга» тирәсенә җитә.

Күрше боярның дүрт яхшы атыны урлап, читкә озатуда буның катышы барлыгы ачыктан-ачык сөйләнә башлагач, мулла, эшнең начарлыгыны сизә дә, Собраниегә үзенең «муллалыкны ташлавы» хакында кәгазь җибәрә[1+].

Һәм шул көннән алып ул мәсҗедкә аяк басмый; кыяфәтене, киемене алыштырып, картлар аның йөзендәге «имансызлыгының» әллә ничә мәртәбә артканыны күрә башлыйлар.

Мулла, михрабтан төшеп, караклар шайкасына керә.

Аны бөтен тирә-як белә, һәр йирдә «карак мулла» дип атап, үзенә ерактан сәлам бирәләр. Бар да беләләр, ләкин эш кыла алмыйлар, чөнки, бердән, байлыгы, партиясе — таянычы зур, икенчедән, мәхәлли түрәләр берлән якын дустлыкта.

**III**

Мулла үз өстеннән пәрдәне алып ташлау берлән, аның үзе һәм бөтен нәселенең караклыгы, анларның кылган батырлыклары, ярым кәрамәтләре[2], алдаулары хакындагы хәбәрләр бөтен тирә-якны тутырды. Ахрысы, халык элек мулла хөрмәтенә бик аз гына яшереп торганнар.

Бунларның бер бабасы булган. Үзе яхшы ук карт икән, шулай да караклыкны куймый икән. Ястүгә азан әйтеп, халык намазга бара башласа, ул үзенең трубкасыны каба да икән, һичкемгә карамыйча, акрын гына авыл буйлап китә икән. Аны ерактан күрүчеләр, бер-берсенә төртеп: «Әнә Юныс карт кәсепкә китте», — диешәләр икән. Якын булсалар, көлмәскә тырышып:

— Юныс бабай, хәерле юл булсын! — диләр икән.

Бу, үзенең заманында караклыкта осталыгы берлән атаклы булган шикелле, әйткән сүзендә торучылыгы, ике сөйләмәве берлән дә гыйбрәт булырлык бер адәм икән.

Аның хакында төрле легендалар бар. Гүя ул бер вакыт үзенең каладагы иптәшләре берлән шундый эш кыйлган:

Уйлаганнар зур бер магазинны алдарга. Күпер астында бер исерек ята икән, ди. Ул үзе телсез булган. Бунлар шуны фатирга алып барып эчергәннәр, ашатканнар, бөтенләй яхшылап киендергәннәр дә, үзенә бераз акча биреп,

---

[1]*Заһир булган* — күренгән.

[2]*Кәрамәтләре* — хикмәтләре.

без кайда утыртсак, мәһабәт кенә утыр, кузгалма, сиңа берни булмас дип, бер зур мануфактур магазинына китергәннәр. Бу бай кыяфәтендә, башкалар ялчы сурәтендә булган. Кергәч, кесәсеннән бер язу чыгарып биргән дә үзе урындыкка утырган. Кесәсеннән дәхи ниндидер кәгазь чыгарып караган була, ди. Ялчылар язу буенча малны төягәннәр дә яшен кеби тизлек берлән сызганнар; бер минуттан анларның эзе дә булмаган. Магазинчылар, бер йөк товар бәрабәренә, өстенә яхшы киенгән, корсагы ясамадан әйбер тутырып зурайтылган телсезне тотып калганнар.

Ул карт, үзе карак булса да, үзенә тапшырылган әйбердә кирәгеннән артыгыны алмый икән. Шунлыктан, авылның зур байлары, андый-бундый хәвефләр ишетелсә, яки үзләре бер якка китәчәк булсалар, Юныс карттан «йортларына күз-колак булу»ны үтенәләр икән. Чөнки болай үтенмәсәләр, ул барыбер урлый һәм бик күп вә бик кызганычсыз урлый, әмма үтенсәләр, байның үз күз алдында алган сыман, гүя хакы бар кеби, зарур кадәрен генә ала да, артыгына үзе дә тими, ул каравыллаган нәрсәгә башкалар да кагыла алмый, байның һәр нәрсәсе исән яши икән.

Бу Тимринең, мулла булуына башта мыек астыннан көлеп йөрсә дә, указыны ташлап, чын кыяфәтене алгач, бик табигый бер эш кеби:

— Безнең йөрәк түзәме соң аңар! — дигәнлекене риваять кылалар[1].

Буны мулла үзе дә тәсдикъ кылды[2].

Бервакыт аңар үз шайкасында булган караклардан берсе:

— Йә инде, мулла, сиңа ни калган безнең берлән йөрергә... дөньяң шәп, йортың бар... нигә сиңа урлашырга, — дигән иде.

Мулла, бу сүзләрнең һәммәсе дөрест булса да, аның караклыгының бик табигый сәбәбе барлыгыны белдерер тарызда[3]:

— Йөрәк түзми, егет, йөрәк түзми! — диде.

**IV**

Карак мулланың торган авылыннан егерме чакрым ераклыкта зур бер авыл булып, аның бер яртысында мукшылар[4], икенче яртысында татарлар яши иде. Һәр ике халык ару гына дәүләтле булсалар да, нәселдән нәселгә игенне алтынга әйләндереп, аны бер дә тотмый саклап килмәктә булган зур бер мукшы бае берлән яңа гына баеп килгән бер татар арасында бик кызу ярышу бара: бунларның һәр икесе ике нәрсәдә — байлык берлән шәп ат асрауда бер-беренең алдына чыгарга тырышалар, мөмкин булган һәрбер адымда берсе икенчесенә аяк салып егарга иҗтиһад кылалар иде.

---

[1]*Риваять кылалар* — сөйлиләр.
[2]*Тәсдикъ кылды* — раслады.
[3]*Тарызда* — рәвештә.
[4]*Мукшылар* — мордвалар.

Бу мәсьәлә халыкка да сираять итеп[1], мукшылар берлән татарлар арасында да бу икенең каюсы алдалыгы хакында талашлар булгалый: аңар шәхси дошман булмаган мукшылар, үзләренең байларыны өсткә чыгарып, аның күмгән алтыны булуыны, һәр ел ындырында иске кибәннәре калуыны сөйлиләр; тик дошманнары гына татар бае Сафаны алга куялар; әмма Сафага шәхси дошман булмаган татарлар аны югары куеп, дәлил урынында йортларының яңалыгыны, зурлыгыны, ялтырап торуыны, збруйларының яхшы булучылыгыны бәян кылалар иде.

Мукшы бае ата-бабадан дәүләтле килеп, бөтен мукшылыкка каршы уларак, искедән бирле өзлексез бер «чабышкы» ат асрыйлар, һәм бу атның һәркайчан бөтен тирә-як чабышкыларыны узарлык булуыны алга тоталар иде.

Бу вакыт анларның зур, биек, назик[2], ләкин бик озын, бик сылу, халык тәгъбиренчә, балык яки сөлек кеби, бер акбүз бияләре булып, бу соңгы өч елда үзеннән алга һичбер атны чыгармаган иде.

Татар бае Сафа, мукшының бу галәбәсенә[3] борыннан ук эчтән янып, яхшы ук хаклар берлән чабышкы атлар алгаласа да, акбүз күк биядән алга чыгарлык мал таба алмый — шулай итеп, бәйрәм гел мукшылар ягында кала иде.

Бер елны авылга чегәннәр килде. Базар көне иде. Сатарга дип, унбишләп җылкы чыгарганнар. Бөтен тирә-якта ат тану берлән даны чыккан Гәрәй картның күзенә бу елкылар эчендә начар гына, ябык кына бер тай чалынган. Карт бер күрү берлән сизеп алган да Сафа байга йөгергән:

— Сафа, Сафа... Бирим дигән колына чыгарып куяр юлына, дигән кеби, Алла сиңа эзләгәнеңне бирде... Чегәннәрдә бер тай бар, ак сакалым берлән әйтәм, ул мукшының биясене бөтенләй оялтыр... Акчаңны ал да әйдә барыйк...

Сафа, картның сүзе берлән, тайны ала. Һәм алданмый. Башка картлар да:

— Ну, Сафа бай, атаң-бабаң күрмәгән, нәселеңә кермәгән мал эләктергәнсең икән, — диләр.

Бу тайдан кечек, чандыр, аз итле, бераз бөкрерәк аркалы, ләкин гаҗиб[4] дәрәҗәдә сөйкемле һәм җанлы бер ат чыга. Ул болай бер төрлерәк кенә, әмма җигеп, яисә менеп чыксаң, шундый матур йөри, бөтен кешеләр исләре китеп карап калалар. Үзе торганы ялкын, шул дәрәҗәдә ки, тик дилбегәңне генә тотып өлгер. Ул кузгала, шул арада әллә кая очкан була.

---

[1]*Сираять итеп* — йогынты ясап.
[2]*Назик* – нәзек.
[3]*Галәбәсенә* — җиңүенә,өстенлегенә.
[4]*Гаҗиб* — искиткеч.

Аның торышыны, аяк атлавыны ук яратып, һәркем аны сөеп:

— Күз тимәсен, — дип кенә сөйлиләр иде.

Бу һәм чабышкы да булып чыга. Авылда зур сабан туе була, шунда бу беренче мәртәбә чабып, мукшының биясе берлән ярышып, тәмам бергә килә. Икенчедә алыннарны буңар бирәләр. Бу, һәр чапканда үзенең куәтен арттыра барып, шәһәр бәйгесендә барлык атларны узып, мукшының акбүз биясен ике чакрым калдырып килә. Бер җәйдә моның шөһрәте чыгып, теге биянең базары төшә, онытылырга якынлый. Бәйрәм татарлар ягына күчеп, мукшылар ул мәсьәләне телгә алмаска тырыша башлыйлар.

Ләкин бай мукшы буны күтәрә алмый, «бирермен әле кирәгеңне» дип, карак муллага мөрәҗәгать итә.

**V**

Карак мулла үзенең табигате берлән, мукшы сүзенә була, бер татарның җаныннан артык күргән малыны юк итәргә риза булачак адәм түгел исә дә, икенче бер сәбәп аны бу сүзгә илтифат итәргә мәҗбүр итте. Шөйлә[1]: бундан өч ел элек тәмам сөкүт[2] берлән кичәрлек бер мәсьәләдә Сафа Тимринең зарарына шәһадәт биреп[3], бик зур эшкә батырган. Бу вакыт мулланың хәяты кыл өстендә генә калып, үзене коткару өчен, әллә ничаклы чыгыннарга мәҗбүр булган иде. Үзенә кылынган усаллыкны һич вә һич бер тәкъдирдә онытачак адәм булмаганга, бердән, үч алу, икенчедән, мукшыдан хезмәт хакы алу фаразы[4] берлән, Тимри мукшының тәклифене[5] кабул итте.

**VI**

Көзнең иң караңгы төннәреннән бере иде. Сәгать өченчеләр булыр. Бу авыл һәм бөтен халык тирән йокыга чумганнар. Шул вакыт мулла иң авыр эшләрдә ышаныч берлән карый торган өч иптәше берлән берлектә теге Сафа байның ындыры артына килеп төштеләр. Берсе салам эскертләре буенда атланып килгән атларыны саклап калды. Өчесе йортка таба киттеләр.

Муллага Сафа байның йорты биш бармак кеби мәгълүм булып, бунларга кирәк булган атның кай йирдә торганлыгы да билгеле иде: ул бер үзе генә башы тимер берлән япкан таш сарайда асрала. Шулай ук Сафаның өрә башласа бөтен авылны җыячак икезур эте барлыгы да мәгълүм иде. Кулларында бунларга дип алынган бераз икмәк булса да, аны азсындылар да, шул йирдә йөргән симез бер башмакны, аягыны бәйләмичә үк, акыртып суеп,

---

[1]*Шөйлә* — шул рәвешчә.
[2]*Сөкүт* — эндәшмәү.
[3]*Шәһадәт биреп* — таныклык итеп.
[4]*Фаразы* — нияте.
[5]*Тәклифене* — тәкъдимен.

үзләре белән бергә алып та килделәр. Бу этләргә бүләк — өрмәү өчен ришвәт иде.

Мулланың атны сарайдан алу хакындагы планы әллә кайчан эшләнгән иде. Ул сарайның ташлыгын, аның калын тимер ишегенең бик артык зур һәм ят йозак берлән бикләнгәнлегене дә белә, һәрхәлдә ишек белән эш итәргә уйламый; аның фаразы болай иде: сарайның башыннан ындырга таба караган ягыны ике аршын кадәрле ачарга, шул ачыктан берничә такта төшереп, анларның бер башыны сарай эченә йиргә, икенче башыны таш стенаның өстенә куярга да, кечек атны егып, аякларыны бәйләп, шул такта өстеннән тышка өстерәп чыгарырга, атның йиргә егылып имгәнмәве өчен, тыш якка да ул шуып китәрлек берничә такта сөяргә. Иштә бөтен план шуннан гыйбарәт булып, аның өчен кирәк мадә[1] һәммәсе хәзер, бик уңгай такталар шул йирдә үк ята иде.

Анлар план буенча эшкә керешкәннәр генә иде.

Йорт ягыннан бер аякның акрын гына бунларга таба атлап килгәне мәгълүм булды. Мулланың колаклары торды:

— Чү, егетләр... Бер гомере беткән бәндә бунда таба килә... Гомәр, ал кистәнне[2], кара, авызыңны ачып калма!

Гомәр бала башыдай зур тимер башлы кистәнне ала да, тыштан илтифатсыз гына торган кеби, әмма эченнән бөтен дикъкатене бер ноктага җыеп, күзләрене астан гына шул якка юнәлдерә.

Аяк якыная, килә, йитә. Ләкин караклар һичбер каушамыйлар. Гәүдә һаман күренми әле, чөнки арада сарай почмагы бар. Бунлар шимале шәркыйгә[3] караган почмакның янында, кояш чыгышы кабыргасы башында, әмма теге аяк төньяк кабырга буйлап килә.

Бик каты бер шакылдый да каравылчы карт килеп чыга. Ул бунларны сизеп түгел, азбарга үз йомышы берлән килә иде. Аңсыздан өч адәм алдына барып чыккач, каушый калды.

— Чү, балалар... нишлисез... мулла... хәзрәт, синме?..

Ашыгып вә ирексез әйтелгән бу сүзләр аның авызыннан чыгып та йитмәде, Гомәр кулындагы кистәннең калын башы берлән картның туры маңлаена төзәп селтәде һәм шулкадәрле тугры, шулкадәрле куәтле һәм муаффәкыятьле[4] булды ки, бабайның башына тиеп, үзене егып ук ташлады. Ул җан ачуы берлән:

---

[1]*Мадә* — кирәк нәрсәләр мәгънәсендә.

[2]*Кистәнне* – фарсы сүзе, чукмарыннан чыгынтылар тырпаеп чыгып торган кыска саплы тимер күсәк – борынгы сугыш коралын.

[3]*Шимале шәркыйгә* — төньяк-көнчыгышка.

[4]*Муаффәкыятьле* — уңышлы.

— Аһ... нахак! — дип бетерергә дә өлгерә алмады, тыны киселде.

Мулла Гомәргә карап:

— Ну, егетсең, егет! — диде. Караклар, гүя бернәрсә дә булмаган кеби, картның янына килеп карамыйча ук, эшләренә тотындылар.

План муаффәкыятьле чыкты. Сарайның карсаклыгы[1], такталарның уңгайлыгы, атның бик кечкенә булучылыгы бунларның эшенә бик күп йиңеллек ясады.

Бунлар ярты сәгать эчендә эшне бетереп, атны чыгардылар да, берсе аны алып китте, мулла берлән Гомәр карт янына килделәр. Мулла аңар аягы берлән төртеп:

— Бичара, үз башыңа килгәнсең икән, — диде һәм, кесәсеннән шырпы алып, аның битенә таба китереп яндырды. Карыйлар — бабай тәмам беткән. Кистәннең калын башы аның башыны урталай ярып, миләре якындагы таш баганага чәчрәгән, күзләре куркыныч үлем сыйфаты берлән акаеп, йөзе кара күгәрә башлаган, теле бик озын булып, авызыннан чыгып, җан ачуы берлән булса кирәк, бик коточкыч рәвештә аркылы тешләнгән.

Мулла, буңа карап йөзен бер генә мәртәбә җыера да, Гомәргә:

— Җирдә ятмасын, эт ашый башлар, билендәге билбавын ал да өрлеккә асып куй! — ди.

Үзе китә. Бер минутта аның боерыгын йиренә йиткереп, Гомәр дә иптәшләре янына бара. Йорт тына. Карт, өрлеккә асылган хәлдә, бик аз гына як-якка тирбәнеп тора.

Караклар, мулланың мукшы берлән булган сөйләшүе буенча, Сафаның атыны авылга каршы тауның нәкъ түбәсенә менгезеп бугазлыйлар да, пычакларыны атның корсагына тыгып, үз авылларына таралалар. Икенче көнне мулла мукшыдан мөкяфәтне[2] алып, өч иптәшенә иллешәр сум акча бирә. Калганы үзенә.

**VII**

Баштанаяк кызыл кан берлән болганган бу вакыйга хәбәре тирә-якны яшен суккан кеби ясады. Халык кайгырыргамы, хәйран калыргамы икәнене белми калды. Картлар, үзләренең хәйрәтене[3] башкача ни дип тә тәгъбир кылып йиткерә алмагач, ике кулларын янбашларына сугалар да:

— Әй, заман, заман! Тагы ниләр күрәсемез бар икән! — диешәләр. Караклар, үзләренең гомер буена кеше талап йөреп тә, шундый бер эш кыла алмауларыны уйлап, эчтән кызыгу хис кылалар. Яшьләр, тыштан яманласалар да, бунлардагы йөрәк вә батырлыкка исләре китәләр. Карчыклар

---

[1]*Карсаклыгы* – тәбәнәк булуы.
[2]*Мөкяфәтне* — хакны.
[3]*Хәйрәтене* — гаҗәпләнүен.

буны ишетү берлән:

— Илаһым, хуҗам... үзең сакла! — дип сыгына башлыйлар.

Балалар вә хатыннар бу дәһшәтне ничек тә башларына сыйдыра, чын итеп аңлаша алмыйлар.

Сафа байның гаиләсене әйтергә дә юк. Анлар бу уйланмаган йирдән килеп чыккан казаны шундый зур бәхетсезлек иттереп хис кылалар ки, халыктан күзләренең яшене яшерергә лязем[1] дә тапмыйлар. Үзләре иркәләп үстереп килгән вә киләчәктә бик зур өмитләр көткән бу «малкай»лары югалса яки урланып читкә җибәрелсә, анлар өчен мең мәртәбә йиңел булачак иде, чөнки бу тәкъдирдә атларының исәнлекене уйлап, бервакыт табылуыны да якын ихтимал тотып җуаныйрлар, өмит берлән алданырлар иде; әмма хәзер, хәзер һичбер өмидкә урын калмаган, анларның яратканнары, юри, мәсхәрә өчен булган кеби, каршыларындагы тауның башына менгезеп бугазланган!

Халык башмак суелу, карт үтерелү, ат бугазлануның барыны бергә җыеп йөртсә дә, Сафа бай гаиләсе өчен иң авыры — соңгысы иде.

Гавамның «кан йибәрми имеш!» дигән бер игътикады[2] бар. Бу вакыйга исә ничектер бундан мөстәсна кеби булып чыкты: никадәрле тырышсалар, әллә нинди юллар берлән эзләп карасалар да, беләгеннән сызганып, кан берлән уйнаган бу вакыйганың каһарманнарыны белү түгел, белү ихтималының эзенә дә керә алмадылар, ягъни һичберәүне тотып гаепләрлек дәлил табылмады.

Тирә-якның әхвалене үтә күреп белгән адәмнәр буның карак мулладан яки аның кулы катышудан башка эшләнә алачак бер дәһшәт түгел икәнене ачык белсәләр дә, тотып бәйләнергә юл булмаганга, бер эш тә кыла алмыйлар иде.

Ләкин эшнең ансат кына сеңеп китүе мөмкин булмады. Авыл йирендә кайбер усалларны, мәхкәмәгә башкача тотып бирә алмасалар, бер карьянең[3] күпчелеге тарафыннан кул куйдырып, «усалның бунда яшәмәвене ил халкы тели», дип кәгазь бирәләр һәм, шулай итеп, илдән сөрәләр. Карак мулладан бөтен тирә-як коты очып торганга, аның хакында күптән үк бундый «ил хөкемен» йөртүне фараз кылучылар бар, хәтта бик күп тә иде. Ләкин һәркем, эшне башлап та очлый алмый калса, мулланың тимер кулына эләгеп, һәлак булачагыны уйлый да ул фаразны тышка чыгара алмый иде.

Бу канлы вакыйганы мулладан дип нык ышанучылар күп булганга, күптән бирле эчләрендә кайнап килгән «теге фараз» ихтыярсыз тышка атылып чыкты. Һәм бер картның башлап телгә алуы берлән, бөтен тирә-як

---

[1]*Лязем* — кирәк.
[2]*Игътикады* — ышануы.
[3]*Карьянең* — авылның.

бер авыздан кушылып, тиз арада, «карак мулланың бу яктан читкә сөрелүене теләп», тау чаклы имзалар җыелды.

Маэмурият[1], бөтен тирә-якка гам булган[2] бу теләкне игътибарсыз калдырырга имкян[3] тапмадыгыннан, карак мулланы бөтен гаиләсе берлән бергә мәңгегә Якутскига сөрде.

Ул китте.

Аның китүе берлән бергә барлык халык өстләреннән бер авырлык төшкәндәге яки араларында яшерен генә рәвештә дәвам кылган бер куркынычтан котылгандагы кеби бер хәл хис кылдылар.

---

[1]*Маэмурият* — монда хөкүмәт органнары, кешеләре мәгънәсендә.
[2]*Гам булган* — халык арасына таралган.
[3]*Имкян* — мөмкинлек.